КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 20 май г.Казань № 342

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Эвакуация комиссиясен төзү турында» 2020 ел, 24 июль, 620 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Эвакуация комиссиясен төзү турында» 2020 ел, 24 июль, 620 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 4 февраль, 55 нче, 2021 ел, 30 декабрь, 1367 нче, 2023 ел, 20 март, 296 нчы, 2023 ел, 11 июль, 810 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Халыкны эвакуацияләү тәртибе, матди һәм мәдәни кыйммәтләр турында» 2004 елның 22 июнендәге 303 номерлы, «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турындагы нигезләмәне раслау турында» 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы карарлары белән» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы, «Халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне имин районнарга эвакуацияләү тәртибе турында» 2023 елның 30 ноябрендәге 2056 номерлы карарлары белән» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Эвакуация комиссиясе турындагы нигезләмәдә:

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Комиссиянең төп бурычлары:

эвакуацияне планлаштыру, әзерләү, оештыру һәм һәрьяклап тәэмин итү;

тиешле дәрәҗәләрдә төзелә торган эвакуация органнары эшчәнлеген координацияләү;

эвакуация чараларын үткәрүне тәэмин итә торган идарә органнары гамәлләренең, көчләр һәм чаралар килештерелүен тәэмин итү.»;

6.1 пунктта:

«а» пунктчасының өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«элемтә бүлеге - ике кеше, шул исәптән «Таттелеком» гавами акционерлык җәмгыятеннән бер кеше (килешү буенча), «Ростелеком» гавами акционерлык җәмгыятеннән - бер кеше (килешү буенча);»;

«д» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«д) юл һәм транспорт белән тәэмин итү төркеме (10 кеше) тулы составта Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан төзелә.

Төркем түбәндәгеләрне үз эченә ала:

юл бүлеге – өч кеше;

пассажирлар йөртү бүлеге - дүрт кеше;

йөк ташу бүлеге - өч кеше;»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Эвакуация комиссиясе составында:

комиссия составыннан Б.Ф.Әскәровны, Р.Д.Габелеваны, Р.Р.Гисмәтовны, Ф.У.Мөхәммәтҗановны, Л.К.Сафиуллинаны чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Зайцев Ярослав Олеговичны | Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының гражданнар оборонасы өлкәсендә вәкаләтләрне тормышка ашыру бүлеге башлыгы урынбасарын, комиссия секретарен |
| Прытков Евгений Александровичны | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Иҗтимагый тәртип саклауны һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары белән җирле үзидарә органнары хезмәттәшлеген оештыру идарәсе башлыгын - комиссия әгъзасын (килешү буенча) |
| Хәбибуллин Ильяс Марсель улын | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе башлыгын – эвакуацияләнә торган халыкның беренчел тормыш эшчәнлеген тәэмин итү төркеме башлыгын |
| Хисаметдинов Марат Нәгыйм улын | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының транспорт идарәсе башлыгын – юл һәм транспорт белән тәэмин итү төркеме башлыгын |
| Шәйдуллов Азат Рамил улын | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының фән, мәгариф һәм инновацион технологияләр бүлеге башлыгын - эвакуацияләнә торган халыкны урнаштыруны оештару төркеме башлыгын; |

Родионов Павла Геннадьевичның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының гражданнар оборонасы өлкәсендә вәкаләтләрне тормышка ашыру бүлеге башлыгын, комиссия рәисе урынбасарын».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин